РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«12» март 2020г. г. Альметьевск №192

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 28 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы 60 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы көрәш турындагы законнарны камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 28 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы 60 нчы номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә Советының 2017 елның 30 мартындагы 74 нче номерлы, 2017 елның 05 маендагы 78 нче номерлы, 2017 елның 31 маендагы 83 нче номерлы, 2017 елның 25 сентябрендәге 91 нче номерлы, 2018 елның 11 маендагы 114 нче номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 135 нче номерлы, 2019 елның 25 мартындагы 146 нчы номерлы, 2019 елның 28 августындагы 168 нче номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга кушымтада:

1.1.1. «Муниципаль хезмәт вазыйфасы» 2 бүлегендәге 2.5 пункты җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2022 елның 1 январенә кадәр муниципаль хокукый актларда муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән һәм (яисә) кече төркеме вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре күрсәтелми (урта гомуми белем булганда), муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасы буенча «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында»2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу шарты үтәлгәндә.»;

1.1.2. «Муниципаль хезмәт белән бәйле тыюларны» 7 бүлегенең 7.1 пункты 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түбәндәге очраклардан тыш катнашырга:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында тезелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу, яллаучы вәкиленең Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә яклау;

г) муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (катнашучы) оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен, я муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә яклау;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;»;

1.1.3. «Муниципаль хезмәткәрнең җаваплылыгы» 22 бүлегенең 22.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22.4. дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә..»;

1.1.4. «Муниципаль хезмәткәрнең җаваплылыгы» 22 бүлек 22.6.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22.6.5. Әлеге нигезләмәнең 8, 22, 24 статьяларында каралган түләтүләр муниципаль хезмәткәрләргә коррупциячел хокук бозуның башкарылуы турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча хезмәткә яраксыз булу чорларын, аның отпускта булуын исәпкә алмаганда һәм коррупциячел хокук бозу башкарылган көннән алып еч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларга җинаять эшен карау вакыты кертелми.».

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның 1 пункты 1.1.1 пунктчасында каралган шартлар 2019 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Бочкарев Н.А.).

Шәһәр Башлыгы «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ» Т.Д. Нагуманов